Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының
«Арча 8нче балалар бакчасы» муниципаль бюджет
мәктәпкәчә белем учреждениесе

# Мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән эшләү өчен татар музыкаль халык уеннары картотекасы

Төзеде:
МБМБУ "Арча 8нче балалар бакчасы" музыка җитәкчесе
Алеева Ләйлә Хөсәен кызы

Арча-2024

**Татар халык уены “Түбәтәй”**

Максат:

- балаларда халык гореф-гадәтләренә хөрмәт хисләре уяту;
- үз-үзләрен тоту һәм узара уңай мөнәсәбәт тәрбияләү;
- татарча дөрес итеп сөйләшә алу мөмкинлекләрен камилләштерү.

Кирәк атрибутлар: Түбәтәй

Балалар түгәрәкләнеп басалар.Түбәндәге җырны җырлый-җырлый, түбәтәйне бар-берсенә бирәләр. Җыр ахырында түбәтәй кемдә калса, шуңа җәза бирелә (бии, җырлый, әтәч булып кычкыра ).

Түбәтәйнекигәнсез,
Бикеракларданкилгәнсез,
Төскәматурлыгыбелән
Шаккатырыйм, дигәнсез.

*Кушымта:*

Түп – түп – түбәтәй,
Түбәтәеңукалы.
Чиккәнматуртүбәтәең
Менәкемдәтукталды.

Музыкасын ВК яйсә яндекстан табып була.

**Түгәрәктә башкарыла торган уен «Әйлән-бәйлән”,**
**Ф. Абубакиров музыкасы, Р. Миннуллин сүзләре**

Максат:

- балаларның җырлау, музыканы тою сәләтләрен үстерү, темплы җырлар аша дөрес дикция булдыру буенча эшләү;

- балаларга эстетик тәрбия бирү, татар милли музыка сәнгатенә ихтирам хисләре тәрбияләү.

Кирәк атрибутлар: “Җырлап-биеп уйныйбыз” дискының 5 нче чыгарылышы “Уйныйк бергә, биик бергә, ямь тулсын яшь күңелгә”

**Татар халык уены “Яулык кая, тап?”**

**Л. Тумашев эшкәртмәсе**

Максат:

- балаларда халык гореф-гадәтләренә хөрмәт хисләре уяту;
- дус, ярдәмчел булырга өндәү, игътибарлы һәм җитез булырга өйрәтү.

Кирәк атрибутлар: кульъяулык.

Балалар түгәрәк ясап басалар. Кулларын артка куялар. Санамыш ярдәмендә яулык салучы билгеләнә. Аның кулында кульъяулык. Ул, түгәрәктән чыгып, шушы сүзләрне җырлап йори:

Кульъяулыгым яшел, яшел,
Яшел чирәм астында.
Сиздермичә ташлап китәм
Бер иптәшем артына.

Сүзләрне әйткәндә, бер баланың уч төбенә кульъяулыкны калдырып китә, үзе түгәрәк эченә кареп баса. Кульъяулыклы бала, тиз генә артка чыгып, сүзләрне әйтә-әйтә, уенны дәвам итәргә тиеш. Әгәр ул тоткарланып торса яки кульъяулык салганны сизмәсә, аңа җәза бирелә.

## Татар халык уены “Оясыз кош”

Максат:

- балаларда халык гореф-гадәтләренә, уеннарына  хөрмәт хисләре уяту;
- дус һәм бердәм  булып уйнарга, игътибарлы һәм җитез  булырга өйрәтү.

Балалар парлашып түгәрәккә басалар: алда басып торганнары  – “оялар”, ә алар артындагылар-“кошлар”. Бер бала парсыз кала, ул - “оясыз кош”

Уенны алып баручы түбәндәге шигырь юлларын сөйли:

Очып баручы кошлар
Туктадылар аланда.
Утырып ял иттеләр,
Кире очып киттеләр.

Оясыз кош түгәрәк тирәли йөри, үзе артыннан калган кошларны иялтә, алар шигырь сүзләренә туры китереп хәрәкәтләр ясыйлар. “Кире очып киттеләр” дигән сүзләрдән соң барысы да ояларына таба йөгерәләр. Оясыз кош буш ояга кереп калырга тырыша. Урынсыз калган бала оясыз кош була, һәм уен дәвам итә.

## Түгәрәктә башкарыла торган уен “Зәңгәр күл”,
## С. Сәйдәшев музыкасы, Г. Насыйри сүзләре

Максат:

- балаларның җырлау,  музыканы тою сәләтләрен үстерү, темплы җырлар аша дөрес дикция булдыру буенча  эшләү;
- балаларга эстетик  тәрбия бирү, татар милли музыка сәнгатенә ихтирам хисләре тәрбияләү.

Кирәк атрибутлар: “Балалар бакчасында әдәп- әхлак тәрбиясе” исемле методик әсбап аудио кушымтасы. № 49, 50

## Татар халык уены “Буш урынлы”

Максат: Йөгереклелек һәм җитезлекне булдыру.

Санамыш ярдәмендә берәүне көтүче итәләр дә, калган балалар бер түгәрәк ясап, бер- берсенең кулларына тотынышып торалар. Көтүче, түгәрәк тышыннан сагалап, түбәндәгечә җырлап йори:

Саескандай чикаклап,
Мин йөримен өй саклап,
Каздай булып кыйгаклап,
Сиңа тиям, син- әбәк!

Шулай дип берсенең аркасына суга да түгәрәк тирәли йөгерә. Әбәк алган бала, урыныннан чыгып, аңар каршы яктан йөгерә. Алдан әйләнеп килеп җиткәне шул буш урынны ала. Урынсыз калганы көтүче була, уен дәвам итә.

## Татар халык уены “Ачык авыз”

Максат: Йөгереклелек һәм җитезлекне булдыру.

Кирәк атрибутлар: Татарча бию көе.

Балалар, аллы-артлы парлашып, түгәрәк ясап басалар. Бер бала парсыз кала. Ул уртада басып тора. Бию көе уйнала. Шул вакытта эчке якта торган балалар түгәрәк ясап җитәкләшәләр һәм бию көенә әйләнәләр. Шулай бераз әйләнгәннән соң, көй кинәт кенә туктала һәм эчке яктагылар тышкы якта басып калган балалар белән парлашалар. Бер бала тагын парсыз кала. Ул, уртага чыгып: “Мин кем?”- дип кычкыра. Иптәшләре аңа: “Ачык авыз син!”- дип җавап бирәләр. Аннан соң “ачык авызның” бер әйбере алына. Уен шулай кабат-кабат уйнала, һәм “ачык авызлар” биш- алтыга җиткәч, аларга җәза бирелә.

**Татар халык уены “Яулык алыш”,**

**татар халык көе, Ф. Залялютдинова эшкәртмәсе**

Максат: Балаларда халык гореф-гадәтләренә хөрмәт хисләре уяту; дус,ярдәмчел булырга өндәү, игътибарлы һәм җитез булырга өйрәтү.

Кирәк атрибутлар: кулъяулык.

Бу уен күбесенчә кыз балалар тарафыннан уйнала. Кызлар бер урынга түгәрәкләнеп басалар һәм бер кешене яулык җыючы итеп сайлап куялар. Ул уртага чыгып баса да:

-Талым, талым, талчыбык,
Уртасында бал чыбык,
Ал яулык, гөл яулык,
Бир син миңа бер яулык,-

Дип, такмаклый-такмаклый, барлык кызлардан да яулык җыеп чыга. Җыеп бетергәч, яулык хуҗаларына берәм-берәм җәза бирелә. Җәзадан соң уен яңадан башлана.

**Түгәрәктә башкарыла торган уен “Кәрия-Зәкәрия”,**

**татар халык җыры, В. Валиева эшкәртмәсе**

Максат:

- балаларны үз-үзләрен тоту һәм узара уңай мөнәсәбәт тәрбияләү;
- татарча дөрес итеп сөйләшә, җырлый алу мөмкинлекләрен камилләштерү.

Кирәк атрибутлар: “Җырлап-биеп уйныйбыз. Без шатлык таратабыз, уйнарга яратабыз” исемле диск, 3 нче чыгарылыш.

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәкләнеп басалар. Уртага бер бала чыга. Түгәрәктәгеләр бер якка хәрәкәт итеп җырлыйлар. Җырларда уртадагы баланың укуда, хезмәттә, җыр-биюдә булган сәләте, уңганлыгы мактала:

Бу бик яхшы биюче,
Бу бик яхшы биюче,
Аның биюе матур,
Аннан үрнәк алыгыз.

Җырдан соң түгәрәктәгеләр туктап калалар, кул чабып, такмак әйтәләр:

Кәрия-Зәкәрия, коммая,
Кәрия-Зәкәрия, коммая,
Кәри комма, Зәкәр комма,
Зәкәрия коммая

Бу вакытта уртадагы бала бер иптәшен алып әйләнеп тора. Әйләнеп туктагач, чакырган иптәшен калдырып, түгәрәккә баса. Тагын җыр башлана:

Бу бик яхшы җырлаучы,
Бу бик яхшы җырлаучы.
Аның җырлавы матур,
Аннан үрнәк алыгыз.

Шулай йөзүче, укучы, буяучы һ.б.

**Хәрәкәтле халык уены “Песи һәм тычканнар”**

Максат:

- дус, ярдәмчел булырга өндәү, игътибарлы һәм җитез булырга өйрәтү.

Кирәк атрибутлар: тычкан һәм песи маскасы.

Уенчылар, кулга-кул тотынышып, түгәрәк ясыйлар. Бер баланы - “тычкан”, икенчесен “песи” итеп билгелиләр. Тычкан песине куа башлый. Балалар

тычканны песидән саклараг, түгәрәк эченә кертмәскә тиешләр. Һәм, киресенчә, тычкан песидән түгәрәк ченә качып котыла ала.

Уен песи тычканны тотканчыга кадәр дәвам итә.

**Түгәрәктә башкарыла торган уен “Кап та коп”**

Максат:

- балаларны үз-үзләрен тоту һәм узара уңай мөнәсәбәт тәрбияләү;
- татарча дөрес итеп сөйләшә, җырлый алу мөмкинлекләрен камилләштерү.

Кирәк атрибутлар: татарча бию көйләре.

Уенчылар түгәрәктә баш бармакларын күрсәтеп түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Без, без, без идек,
Без унике кыз идек.
Базг атөштек май ашадык,
Келәткә кердек бал каптык,
Кап та коп, авызыңны ач та йом!

Балалар уен сүзләрен көйләп әйтәләр, аннары, берьюлы авызларын йомып, җиңелчә, күңелле көйгә төрле шаян хәрәкәтләрясыйлар. Кем көлеп җибәрә, шул уеннан чыга һәм җәза үтәргә тиеш була (җырлый, бии һ.б.)

**Татар халык уены “Мәликә”,**
**Ф. Шәймарданова музыкасы, халык сүзләре**

Максат:

- балаларда халык гореф-гадәтләренә хөрмәт хисләре уяту;
- үз-үзләрен тоту һәм узара уңай мөнәсәбәт тәрбияләү;
- татарча дөрес итеп сөйләшә, җырлый алу мөмкинлекләрен камилләштерү.

Балалар түгәрәккә басалар. Берәү, күзен бәйләп, түгәрәк уртасына утыра. Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәктә килешле татар халык көенә җырлап әйләнәләр:

Утыр, утыр, Мәликә, алмагачның төбенә,
Кем утырган каршыңа, әйтеп бирче тиз генә.

Берәү аның янына килеп утыра. Уртадагы бала аның каршыдагы исемен әйтергә тиеш. Әгәр белмәсә, аңа җәза бирелә. Уен шул рәвешчә дәвам итә.

**Татар халык уены “Үзеңә пар тап”,**
**татар халык көе, Ф. Залялютдинова эшкәртмәсе**

Максат:
- балаларны игътибарлы һәм җитез булырга өйрәтү.

Кирәк атрибутлар: татарча бию көйләре.

Балалар зур түгәрәк ясап басалар. Физкультура дәресен искә төшереп 1,2 дип санап чыгалар. Беренчеләр бер адым алга чыга, икенчеләрурында кала. Шулай итеп ике түгәрәк барлыкка килә. Беренчеләр бер якка биеп китә, икенчеләр икенче якка биеп китәләр. Көй туктауга парлашып әйләнергә кирәк.

**Түгәрәктә башкарыла торган уен**
**“Чума үрдәк, чума каз”**

Максат:
- балаларны үз-үзләрен тоту һәм узара уңай мөнәсәбәт тәрбияләү;
- татарча дөрес итеп сөйләшә, җырлый алу мөмкинлекләрен камилләштерү.

Кирәк атрибутлар: “Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе” исемле методик әсбап аудио кушымтасы. № 137,138

Уйнаучылар кара-каршы ике рәт булып тезеләләр, парлашып кулга кул тотыналар. Рәт башында бер ялгыз уенчы басып тора. Балалар барысы бергә җырлыйлар:

Чума үрдәк, чума каз,
Тирән күлне ярата ул, ярата.
Әлфия үзенә иптәш эзли,
Белмим, кемне ярата шул, ярата.
Илназны ярата шул, ярата.

Уйнаучылар, җыр ритмына туры китереп, хәрәкәтләнеп торалар. Ялгыз бала (Әлфия), рәт арасыннан узып, үзенә бер иптәш сайлый һәм аны (Илназны) җитәкләп ахырга барып баса. Үз парыннан аерылган уйнаучы рәт башына китә.

Уен шулай дәвам итә.

**Татар халык уены “Дустым бар”,**
**Л. Батыр- Булгари музыкасы, халык сүзләре**

Максат:
- балаларны үз-үзләрен тоту һәм узара уңай мөнәсәбәт тәрбияләү;
- татарча дөрес итеп сөйләшә, җырлый алу мөмкинлекләрен камилләштерү.

Кирәк атрибутлар: "Без шатлык таратабыз, уйнарга яратабыз" (диск №3, 3 яшьтән 5 яшькә кадәр). Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен җырлы-биюле уеннар аудио җыентыгы.

Балалар түгәрәктә басып җырлыйлар. Түгәрәк буенча хәрәкәтләнәләр.

**Хәрәкәтле уен “Куышу”**

Максат:

балаларны игътибарлы һәм җитез булырга өйрәтү.

Кирәк атрибутлар: татарча бию көйләре.

Уен мәйданчыгының кара-каршы ике ягына сызык сызып, уйнаучылар өчен урын билгеләнә. Бу - “өйләр”. Барлык уйнаучылар бер өйгә җыелып, тезелешеп басалар. Бер бала уенны алып баручы итеп билгеләнә. Ул ике өй арасында, уйнаучыларга өйзе белән борылып, уртада басып тора.

Йөгерешеп, куышып,
Бергәләп уйнап алыйк.
Кем кыю, өлгер, җитез-
Әйдәгез, сынап карыйк!

Әлеге сүзләрне әйтеп бетерүгә, барлык уенчылар да каршы яктагы өйгә йөгерешә башлыйлар. Алып баручы кемне дә булса тотарга тырыша. Тотылган бала уенны алып баручы була. Уен шулай дәвам итә. Уен ахырында иң өлгер, иң җитез балалар билгеләнә.

**Түгәрәктә башкарыла торган уен “Зәңгәр чәчәк”,**
**Ф. Шаймарданова музыкасы, халык сүзләре**

Максат:

- балаларны үз-үзләрен тоту һәм узара уңай мөнәсәбәт тәрбияләү;
- татарча дөрес итеп сөйләшә, җырлый алу мөмкинлекләрен камилләштерү.

Кирәк атрибутлар: “Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе” исемле методик әсбап аудио кушымтасы. № 51,52

Балалар плюсовкага кушылып җырлыйлар, текст буенча хәрәкәтләр ясыйлар.

**Хәрәкәтле уен “Карусель”**

Максат:
тел өйрәнү, татар телендә аралашу теләге тудыру.

Кирәк атрибутлар: шнур.

Уйнаучылар түгәрәккә басалар. Тәрбияче балаларга ике очы бергә бәйләнгән шнур бирә. Балалар, уң куллары белән шнурга тотынып, сулга борылалар да түбәндәге сүзләрне әйтәләр:

Әллә-лә, әллә-лә,
Карусельләр әйләнә!
Аннары борылабыз,
Бик каты йөгерәбез.

Балалар, шигырьнең эчтәлегенә туры китереп, башта әкрен генә, аннары кызурак йөриләр, ә соңыннан йөгерәләр.

**Хәрәкәтле уен “Кулъяулык”**

Максат:
балаларны игътибарлы һәм җитез булырга өйрәтү.

Кирәк атрибутлар: татарча бию көйләре.

Уйнаучылар көй астында – зур түгәрәктә, ә уенны алып баручы түгәрәк уртасында бию хәрәкәтләре ясап әйләнәләр. Көй туктауга, уенны алып баручы бер бала янына килә дә: “Яулыгымны ал, кесәңә сал”,- ди. Балалар:

“Бер, ике,өч, дүрт, биш, тотарга тырыш!”,-диюгә, бала уенны алып баручыны тотарга һәм яулыкны аннан алырга тырыша.

**Түгәрәктә башкарыла торган уен “Шома бас”**

Максат:

- балаларны үз-үзләрен тоту һәм узара уңай мөнәсәбәт тәрбияләү;
- татарча дөрес итеп сөйләшә, җырлый алу мөмкинлекләрен камилләштерү;
- татар көенә килешле хәрәкәт итергә өйрәтү.

Балалар кызлар һәм малайларга бүленеп, кара-каршы басалар, җырны чиратлап башкаралар, тәрбияче күрсәткән бию хәрәкәтләрен кабатлыйлар.

Уйнат, уйнат гармуныңны,

Биесеннәр егетләр.
Безнең илнең егетләре
Бары да бөркет кебекләр.

Их, күңел ачабыз,
Ничек шома басабыз!

Сайрат, сайрат гармуныңны,
Җилкенсеннәр яшь кызлар.
Безнең кызлар нурлы йөзле,
Әйтерсең лә йолдызлар.

Их, күңел ачабыз,
Ничек шома басабыз!

Шаулат, шаулат бию көен,
Ашыксыннар барысы да;

Яшь егетләр чакырсыннар,
Кызлар чыксын каршыга.

Их, күңел ачабыз,
Ничек шома басабыз!

Әйдә, әйдә, катырак бас,
Биегәнне күрсеннәр;
«Баскан җирдән ут чыгара
Безнең яшьләр», — дисеннәр.

Их, күңел ачабыз,
Ничек шома басабыз!

Макта, макта, безнең яшьләр
Ничек җитез атлыйлар!
Биергә дә оста алар,
Эштә дә сынатмыйлар.

Их, күңел ачабыз,
Ничек шома басабыз!

**Татар халык уены “Төймә”**

Максат:
- балаларны үз-үзләрен тоту һәм узара уңай мөнәсәбәт тәрбияләү;
- татарча дөрес итеп сөйләшә, җырлый алу мөмкинлекләрен камилләштерү;
- татар көенә килешле хәрәкәт итергә өйрәтү.

Балалар, түбәндәге сүзләрне җырлап, түгәрәктә әйләнеп йөриләр һәм, туктап, кушымтасында бииләр:
Яңгыр ява сибәләп,
Төймә, төймә, төймәләп.

Их, төймә,төймә,төймә,

Төймә була егерме.

Кушымта: Бергә җырлыйк, бергә уйныйк,

Бергә яшәү күңелле.

Җепкә тезгән төймә кебек,

Без  дә яшик бергәләп.

Кушымта: Их, төймә,төймә,төймә,

Төймә була бер җептә.

Җепкә тезгән төймәләрнең,

Матурлыгы берлектә.

**Түгәрәктә башкарыла торган уен**

**“Эх, зилем-зиләлем”,**

**татар халык уен җыры**

Максат:

- балаларны үз-үзләрен тоту һәм узара уңай мөнәсәбәт тәрбияләү;
- татарча дөрес итеп сөйләшә, җырлый алу мөмкинлекләрен камилләштерү;
- татар көенә килешле хәрәкәт итергә өйрәтү.

Кирәк атрибутлар: “Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе” исемле методик әсбап аудио кушымтасы. № 143,144

Балалар плюсовкага кушылып җырлыйлар, текст буенча хәрәкәтләр ясыйлар.